**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в статьи 6 и 14 Закона Республики Татарстан «О физической культуре и спорте»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
21 июня 2018 года

## Статья 1

Внести в Закон Республики Татарстан от 8 октября 2008 года № 99-ЗРТ «О физической культуре и спорте» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2008, № 10 (I часть); 2010, № 6 (I часть); 2011, № 5; 2012, № 7 (I часть), № 12 (II часть); 2013, № 6 (II часть); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II часть); 2015, № 3, № 7 (I часть), № 10 (I часть), № 11 (I часть); 2016, № 3, № 10; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 27 (часть I); 2018, № 29 (часть I) следующие изменения:

1) в статье 6:

а) пункт 6 части 1 после слов «спортивных разрядов» дополнить словами «, квалификационных категорий тренеров, квалификационных категорий специалистов в области физической культуры и спорта»;

б) часть 2 дополнить пунктом $4^1$ следующего содержания:

«$4^1$) участвовать в организации и проведении межрегиональных, всероссийских и международных спортивных соревнований среди студентов (в том числе среди студенческих спортивных лиг), проводимых на территории Республики Татарстан;»;

2) в статье 14:

а) наименование изложить в следующей редакции:

«Статья 14. **Спортивные звания, спортивные разряды. Квалификационные категории спортивных судей, тренеров и специалистов в области физической культуры и спорта**»;

б) часть 1 изложить в следующей редакции:

«1. В Республике Татарстан устанавливаются спортивные звания, спортивные разряды, а также квалификационные категории спортивных судей, тренеров и специалистов в области физической культуры и спорта в соответствии с законодательством Российской Федерации.»;

в) в части 3 слова «к кандидатам на присвоение данных категорий» заменить словами «к присвоению соответствующих категорий»;

г) дополнить частью 6 следующего содержания:

«6. Квалификационные категории тренерам и специалистам в области физической культуры и спорта присваиваются в соответствии со статьей 22 Федерального закона. Квалификационные категории «тренер высшей квалификационной категории», «тренер первой квалификационной категории», «специалист в области физической культуры и спорта высшей квалификационной категории», «специалист в области физической культуры и спорта первой квалификационной категории» присваиваются соответственно тренерам и специалистам в области физической культуры и спорта, осуществляющим свою деятельность в организациях, в отношении которых федеральные органы исполнительной власти не осуществляют функции и полномочия учредителя, специально уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан в области физической культуры и спорта.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
30 июня 2018 года
№ 44-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Физик культура һәм спорт турында”
Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 14 статьяларына
үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Физик культура һәм спорт турында” 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:

а) 1 өлешнең 6 пунктында “спорт разрядлары” сүзләреннән соң “, тренерларның квалификация категорияләре, физик культура һәм спорт өлкәсендәге белгечләрнең квалификация категорияләре” сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

“$4^1$) Татарстан Республикасы территориясендә студентлар арасында (шул исәптән студентларның спорт лигалары арасында) үткәрелә торган регионара, гомумроссия һәм халыкара спорт ярышларын оештыруда һәм үткәрүдә катнашырга;”;

2) 14 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“14 статья. **Спорт дәрәҗәләре, спорт разрядлары. Спорт судьяларының, тренерларның һәм физик культура һәм спорт өлкәсендәге белгечләрнең квалификация категорияләре**”;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Татарстан Республикасында спорт дәрәҗәләре, спорт разрядлары, шулай ук спорт судьяларының, тренерларның һәм физик культура һәм спорт өлкәсендәге

белгечләрнең квалификация категорияләре Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.”;

в) 3 өлештә “шушы категорияләрне бирү өчен кандидатларга карата” сүзләрен “тиешле категорияләрне бирү өчен” сүзләренә алмаштырырга;

г) түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

“6. Тренерларга һәм физик культура һәм спорт өлкәсендәге белгечләргә квалификация категорияләре Федераль законның 22 статьясы нигезендә бирелә. “Иң югары квалификация категориясендәге тренер”, “беренче квалификация категориясендәге тренер”, “физик культура һәм спорт өлкәсендә иң югары квалификация категориясендәге белгеч”, “физик культура һәм спорт өлкәсендә беренче квалификация категориясендәге белгеч” квалификация категорияләре тиешенчә физик культура һәм спорт өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең махсус вәкаләтле органы тарафыннан федераль башкарма хакимият органнары гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкармый торган оешмаларда үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы тренерларга һәм физик культура һәм спорт өлкәсендәге белгечләргә бирелә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 30 июнь
№ 44-ТРЗ